Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе “Кукмара 3 нче номерлы урта мәктәбе”

# Тема: “Татар мәдәниятен саклау һәм үстерү”




**Эшне башкарды:**
**11 нче сыйныф укучысы**
**Муллиева Руфинә Райнур кызы**
**Фәнни җитәкче:**
**туган тел һәм әдәбият укытучысы**
**Гатауллина Лилия Фоат кызы**

**2026**


**Проектның максаты**: Татар халкының электән килгән гореф-гадәтләрен , мәдәниятен һәм йолаларын популярлаштыру, бүгенге көн яшьләрендә төрле платформалар ярдәмендә әлеге бәйрәмнәргә кызыксыну өчен шартлар тудыру.

# Социологик сораштыру

**Мин үзебезнең гаиләнең традицион кыйммәтләрен өйрәнү дәверендә 11а,б сыйныфы укучылары арасында сораштыру үткәрдем. Анкета сорауларына 50 укучы җавап бирде. Анкетада түбәндәге сораулар бар иде.**





**Халкыбызның гореф-гадәтләре, йола-бәйрәмнәре турында сез беләсезме?**




**Халкыбызның йолаларын саклауга без өлеш кертә алабызмы?**

**Сезнең гаиләдә гореф –гадәтләр, йолалар үткәреләме?**



**Проектның бурычлары:**

1) тәрбия традицияләренә нигезләнеп халкыбызның гореф- гадәтләрен, бәйрәмнәрен белү, алар белән кызыксынуларын үстереп яшьләрдә эстетик һәм әхлакый тәрбия булдыру;

2) татар халкының милли бәйрәмнәре, йола уеннары, гореф- гадәтләре аша яшьләрнең аралашу, коммуникатив осталыгын, сөйләм телен үстерү;

3)халкыбызның милли тадицияләрен саклау максатыннан ел фасыллары белән бәйләнешле йола- бәйрәмнәре ( “ Каз өмәсе”, “ Карга боткасы”, Нәүрүз”. “Сабантуй”) белән яшьләрне таныштыру.

# Проектның актуальлеге

Әлеге проект бүгенге көндә бик актуаль, чөнки үз тарихын белмәгән халыкның киләчәге юк. Моның өчен һәр бала үз гаиләсенең, туган җиренең тарихын белергә, шуның аша халыкка якынаерга тиеш.
Һәр милләт үз җирлегендә барлыкка килгән һәм буыннан-буынга күчә торган гореф-гадәтләрен, кешеләрнең яшәү рәвешләрен, үз-үзләрен тоту кагыйдәләрен, карашларын, зәвыкларын сакларга омтылган. Тормыш–көнкүрештә билгеле бер йолалар үтәү, гореф-гадәтләрне тоту һәм бәйрәмнәр үткәрү барлык милләтләргә дә хас. Ул әлеге милләт мәдәниятенең мөһим бер өлеше булып исәпләнә. Гореф-гадәтләр борын-борыннан халык тарафыннан үтәлеп килә торган бәйрәмнәрне, йолаларны үз эченә ала. Билгеле бер йолаларның үтәлеп килүе җәмгыятьне дә тотрыклы итә, алардан башка халык тулы кыйммәтле тормыш белән яши алмый.

# Милли бәйрәмнәр:
# “Каз өмәсе”





# Милли бәйрәмнәр:
# “Карга боткасы”





# Милли бәйрәмнәр: “Сабантуй”





# Милли бәйрәмнәр: “Сабантуй”

## Аркан тартыш



Бигрәк юан арканы!
Бармы икән тартканың?
Тезелдек ике сафка,
Бүлендек ике якка.
Уртада торак – таяк,
Билгегә дигән маяк.
И, арканны тартабыз,
Тирләп чыкты аркабыз.
Бер маякка җитәбез,
Аннан артка китәбез...
Тырыша торгач шулай,
Ахры, җиңәбез бугай!
Уйлап та өлгермәдем,
Чирәмгә тәгәрәдем!

# Милли бәйрәмнәр:
# “Нәүрүз”

## Нәүрүз бәйрәме

***Нәүрүз – язны каршылап, язгы чәчү эшләре алдыннан үткәрелә торган халык бәйрәме ул. Нәүрүз сүзе яңа көн (ел) дигәнне аңлата. Нәүрүз бәйрәме – ул игелек, дуслык бәйрәме. Бу гүзәл, язгы бәйрәм көнендә кешеләр бер-берсенә кунакка йөриләр, бер-берсенә булган үпкәләрен оныталар, җырлыйлар , бииләр, рәхәтләнеп күңел ачалар. Бу бәйрәмнең хуҗасы- Нәүрүзбикә.***







**Игътибарыгыз өчен рәхмәт!**